Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге Советы

КАРАР

«15» апрель, 2025 ел №5

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун ел вакытка расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 19 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (kukmor.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә түбәндәге адресларда урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

Вахитов ав., Клуб ур., 12 й. (административ бина);

Янил ав., Мәктәп ур., 18 й. (Мәдәният йорты бинасы).

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Җирлек башлыгы И.Х. Корбанов

Татарстан Республикасы Кукмара районы
Янил авыл җирлеге Советының 2025 елның 15
апрелендәге 5 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

1 номерлы бермандатлы Татарстан сайлау округы

Сайлаучылар саны – 120

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Янил авылы (Татарстан урамының 1 - 52 нче, Үзәк урамның 10, 11 нче йортлары).

2 номерлы бермандатлы Үзәк сайлау округы

Сайлаучылар саны – 118

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Янил авылы (Мәктәп урамының 1 - 17 нче, Үзәк урамның 9, 12 - 24 нче, Почта урамының 1 - 14 нче йортлары).

3 номерлы бермандатлы Яшьләр сайлау округы

Сайлаучылар саны – 116

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Янил авылы (Яшьләр урамының 1 - 42 нче, Каенлы урамының 1 - 6 нчы йортлары).

4 номерлы бермандатлы Мәктәп сайлау округы

Сайлаучылар саны – 119

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Янил авылы (Профтехквартал урамының 1 - 20 нче, Яр буе урамының 1 - 14 нче, Елга урамының 1 - 5 нче, Яңа урамның 1 - 7 нче, Үзәк урамның 1 - 8 нче йортлары), Бөяр поселогы

5 номерлы бермандатлы Октябрь сайлау округы

Сайлаучылар саны – 116

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Вахит авылы (Октябрь урамының 1 - 38 нче, Клуб урамының 1 - 4 нче, Тукай урамының 1 - 16 нчы йортлары).

6 номерлы бермандатлы Яр буе сайлау округы

Сайлаучылар саны – 101

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Вахит авылы (Урман урамының 1 - 5 нче, Яр буе урамының 1 - 21 нче, Чишмәле урамының 1 - 14 нче йортлары).

7 номерлы бермандатлы Беренче Май сайлау округы

Сайлаучылар саны – 106

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Вахит авылы (Беренче Май урамыың 18 - 56 нчы йортлары).

8 номерлы бермандатлы «Айнур» сайлау округы

Сайлаучылар саны – 102

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Вахит авылы (Яшьләр урамыың 1 - 35 нче йортлары).

9 номерлы бермандатлы Елга сайлау округы

Сайлаучылар саны – 103


Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Вахит авылы Татарстан урамының 1 - 20а, Яшьләр урамының 36 - 38 нче, Елга урамының 1 - 19 нчы йортлары).

10 номерлы бермандатлы Яшел сайлау округы

Сайлаучылар саны – 104

Округка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясе түбәндәге чикләрдә керә: Вахит авылы (Каенлы урамының 1 - 15 нче, Беренче Май урамының 1 - 17 нче, Яшел урамның 1 - 6 нчы йортлары).

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте




| № Округа | Название округа |
|---|---|
| 1 | Татарстанский |
| 2 | Центральный |
| 3 | Молодежный |
| 4 | Школьный |
| 5 | Октябрьский |
| 6 | Набережный |
| 7 | Первомайский |
| 8 | Айнур |
| 9 | Речной |
| 10 | Зеленый |